**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 11 сентябрендәге 3850 номерлы карары**

# Казанда «Казан ярыммарафоны – 2024» җиңел атлетика чарасы үткәрү, чараны әзерләү һәм үткәрү чорына транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында

1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы «Юл хәрәкәте иминлеге турында»гы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы, 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турындагы һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы федераль законнар һәм 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында»гы Татарстан Республикасы законы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартындагы 159 номерлы «“Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү” Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында»гы карары нигезендә, Казан шәһәрендә сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, халыкны физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү, җиңел атлетика белән шөгыльләнүне популярлаштыру максатыннан:

1. **Карар бирәм**:

1.1. әлеге карарның 1 номерлы кушымсы нигезендә Казан шәһәрендә «Казан ярыммарафоны – 2024» җиңел атлетика чарасын әзерләү һәм үткәрү вакытында транспорт чаралары хәрәкәтен чикләүне кертергә:

- 2024 елның 22 сентябрендә 06:30 сәгатьтән 09:00 сәгатькә кадәр Вишневский урамы буенча (Н.Ершов урамындагы чыгу юлыннан алып «Миллениум» күперенә кадәр юнәлештә, хәрәкәтне чикләү);
- 2024 елның 22 сентябрендә 06:30 сәгатьтән 09:00 сәгатькә кадәр Вишневский урамы буенча (Вишневский урамыннан алып «Миллениум» күперенә кадәр юнәлештә, хәрәкәтне чикләү);
- 2024 елның 22 сентябрендә 06:30 сәгатьтән 09:00 сәгатькә кадәр «Миллениум» күпере буенча (хәрәкәтне тулысынча чикләү);

- 2024 елның 22 сентябрендә 06:30 сәгатьтән 09:00 сәгатькә кадәр Подлужная урамы буенча (Подлужная урамындагы 67 номерлы йорттан алып «Миллениум» күперенә кадәр юнәлештә, хәрәкәтне чикләү);

- 2024 елның 22 сентябрендә 06:30 сәгатьтән 09:00 сәгатькә кадәр Ф.Әмирхан урамы буенча («Миллениум» күперенә тоннельгә керү юлыннан алып «Миллениум» күперенә кадәр, хәрәкәтнең ике юнәлешен тулысынча чикләү);

- 2024 елның 22 сентябрендә 06:30 сәгатьтән 10:00 сәгатькә кадәр «Миллениум» күпере астындагы автомобиль юлы буенча (С.Хәким урамындагы «Ривьера» аквапаркы яныннан алып А.Козин урамындагы 2 номерлы йорт һәм Ф.Әмирхан урамындагы 1Г номерлы йорт арасындагы урамга кадәр юнәлештә, хәрәкәтне чикләү);

- 2024 елның 22 сентябрендә 06:30 сәгатьтән 10:00 сәгатькә кадәр Ф.Әмирхан урамы буенча (А.Козин урамындагы 2 номерлы йорттан алып С.Хәким урамына кадәр юнәлештә, хәрәкәтне чикләү);

- 2024 елның 22 сентябрендә 06:30 сәгатьтән 10:00 сәгатькә кадәр С.Хәким урамы буенча (Ф.Әмирхан урамыннан алып Чистай урамы белән кисешү юлына кадәр юнәлештә, А.Козин урамы һәм Нигъмәтуллин урамы ягыннан үтәли чыгу мөмкинлеге белән хәрәкәтнең ике юнәлешен чикләү);

- 2024 елның 22 сентябрендә 06:30 сәгатьтән 10:00 сәгатькә кадәр Чистай бożрасы буенча (С.Хәким урамына чыгу юлыннан алып Чистай урамына чыгу юлына кадәр, хәрәкәтнең ике уң полосасын чикләү);

- 2024 елның 22 сентябрендә 06:30 сәгатьтән 10:00 сәгатькә кадәр Чистай урамы буенча (Чистай боҗрасыннан алып «Ак Барс Арена» стадионы тирәли әйләнешкә чыгу юлына кадәр юнәлештә, хәрәкәтнең өч уң полосасын чикләү);

- 2024 елның 22 сентябрендә 06:30 сәгатьтән 10:00 сәгатькә кадәр «Ак Барс Арена» стадионы тирәли (хәрәкәтне тулысынча чикләү);

- 2024 елның 22 сентябрендә 06:30 сәгатьтән 10:30 сәгатькә кадәр С.Хәким урамы буенча (Декабристлар урамыннан алып Ф.Әмирхан урамына кадәр юнәлештә, хәрәкәтнең ике юнәлешен чикләү);

- 2024 елның 22 сентябрендә 07:00 сәгатьтән 10:50 сәгатькә кадәр Декабристлар урамы буенча (Кремль дамбасыннан алып Чистай урамына кадәр юнәлештә, хәрәкәтнең ике юнәлешен туктатып тору);

- 2024 елның 22 сентябрендә 07:00 сәгатьтән 10:50 сәгатькә кадәр Кремль дамбасы буенча (С.Хәким урамыннан алып Ташаяк урамына кадәр юнәлештә, хәрәкәтнең ике юнәлешен туктатып тору);

- 2024 елның 22 сентябрендә 07:00 сәгатьтән 10:50 сәгатькә кадәр Пролетарская урамы буенча (хәрәкәтнең ике юнәлешен туктатып тору);

- 2024 елның 22 сентябрендә 07:00 сәгатьтән 10:50 сәгатькә кадәр Батурин урамыннан алып Кремль дамбасына менү юлында (хәрәкәтне чикләү);

- 2024 елның 22 сентябрендә 07:00 сәгатьтән 10:50 сәгатькә кадәр Кремль дамбасыннан алып Кремль яр буена таба чыгу юлында (хәрәкәтне чикләү);

- 2024 елның 22 сентябрендә 07:00 сәгатьтән 10:50 сәгатькә кадәр автомобиль юлы буенча (Ташаяк урамыннан алып Кремль дамбасына (Меңьеллык мәйданы) кадәр юнәлештә), хәрәкәтнең ике юнәлешен туктатып тору);

- 2024 елның 22 сентябрендә 07:00 сәгатьтән 10:50 сәгатькә кадәр автомобиль юлы буенча (Меңьеллык мәйданыннан алып Батурин урамына кадәр юнәлештә чыгу юлында, хәрәкәтне чикләү);

- 2024 елның 22 сентябрендә 07:00 сәгатьтән 10:50 сәгатькә кадәр Батурин урамы буенча (К.Маркс урамыннан алып Кремль яр буена кадәр юнәлештә, хәрәкәтнең ике юнәлешен чикләү);

- 2024 елның 22 сентябрендә 07:00 сәгатьтән 10:50 сәгатькә кадәр Кремль яр буе буенча (Батурин урамыннан алып Сәетгалиев урамына кадәр, хәрәкәтнең ике юнәлешен чикләү);

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитетына (Л.З.Гарипов) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

1.2.1. әлеге чараны әзерләүдә һәм үткәрүдә ярдәм итәргә;

1.2.2. Интернет челтәрендә «Татарстан Республикасының рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында мәгълүматны урнаштырырга;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров) транспорт предприятиеләренә юлларны ябу һәм җәмәгать транспорты маршрутларын үзгәртү турында хәбәр итәргә, дистанция маршруты буенча юл билгеләрен урнаштыруны, сүтүне, каплауны һәм ачуны килештерергә, шулай ук катнашучылар хәрәкәтенең бөтен маршруты буенча яктыртуны тәэмин итәргә;

1.4. әлеге карарның 2 номерлы кушымсы нигезендә Казан шәһәре Башкарма комитеты районнары администрацияләренә (Р.Х.Шәмсетдинов, А.И.Салихов, В.В.Жаворонков, Р.Р.Фәтхетдинов) юлларны ябу өчен йөк техникасы белән тәэмин итәргә;

1.5. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (И.И.Сәләхетдинов) ярышлар маршруты буенча ремонт-төзелеш эшләрен үткәрү графигына төзәтмәләр кертергә, чараны әзерләгәндә транспортның керү юлларын һәм машина кую урыннарын төзекләндерү буенча комплекслы чаралар үткәрергә, чүп баклары белән тәэмин итәргә һәм үткәрү урыннарында чүп чыгаруны тәэмин итәргә, чара тәмамланганнан соң, үткәрү урыннарына якын урам-юл челтәре объектларын җыештыруны тәэмин итәргә, Казан шәһәре Башкарма комитеты районнарының администрацияләре белән берлектә йөк техникасы белән юлларны ябуга ярдәм итүне оештырырга;

1.6. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм:**

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Н.Д.Закиров) әлеге чараны әзерләү һәм үткәрү урыннарында җәмәгать тәртибен саклауны оештырырга, әлеге карарның 1.1 пунктында күрсәтелгән Казан шәһәренең урам-юл челтәре участоклары буенча транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү чорында юл хәрәкәте иминлеген тикшереп торуны тәэмин итәргә;


2.2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсенә (В.С.Филатов) әлеге чарада катнашучыларга медицина хезмәте күрсәтүне тәэмин итәргә (шартнамә нигезендә);

2.3. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) спортчылар хәрәкәте вакытында күрсәтелгән участоклар буенча транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләү кертү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 11 сентябрендәге 3850 номерлы карарына 1 номерлы кушымта



Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 11 сентябрендәге
3850 номерлы карарына 2 номерлы кушымта

